**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «15» мартыннан № 65

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 сентябрендәге 1002 номерлы карары нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 6 маендагы 380 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, 2020 елның 01 сентябрендәге 768 номерлы, 2020 елның 03 ноябрендәге 989 номерлы, 2021 елның 21 июлендәге 633 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2001 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 гыйнварындагы 16 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт

оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү»

1. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | - | 16 155 | 18 382 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (җитештерү)остаханәсе һәм гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) тарафыннан | - | - | 18 463 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | - | - | 18 526 |

2. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 16 388 | 16 899 | 17 199 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Тавыш операторы | 16 388 | 16 388 | 16 388 |
| Рәссам-бизәүче | | | |

3. Спорт резервын әзерләү оешмалары медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 18 900 |
| «Табиблар һәм провизорлар» профессиональ квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 20 600 |
| <*> Вазыйфа оешмада кул астында өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булган очракта билгеләнә. | | |

4. Спорт резервын әзерләү оешмаларында физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 15279,0 | - | - |
| | Беренче төркем инвалидлыгы булган инвалид спортчыны озата баручы | | - | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 15279,0 | - | - |
| | Әйдәүче спортчы | | - | - |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура инструкторы | 15 279 | 16 142 | 18 362 |
| | Спорт инструкторы | - | 16 142 | 18 362 |
| | Спортчы-инструктор | 15 279 | - | |
| | Атны өйрәтүче тренер | 15 279 | 16 142 | - |
| | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | - | 16 142 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тренировкалар процессы администраторы | - | 16 149 | 18 382 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструкторы-методисты | - | 16 149 | 18 382 |
| | Адаптив физик культура инструктор-методисты | - | 16 149 | 18 382 |
| | Тренер | - | 16 149 | 18 382 |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | 16 149 | 18 382 | |
| | Хореограф | | 16 149 | 16 149 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | - | 16 155 | 18 394 |
| | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструкторы-методисты | - | 16 155 | 18 394 |
| | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | - | 16 155 | 18 394 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төре яки спорт төрләренең төркеме буенча) | - | - | 18562 |

2. 27 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 таблица

Спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчеләренең башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме.

| Җитәкче хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләмле күрсәткечнең күрсәткече (дәүләт биреме нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә торышы буенча шөгыльләнүчеләр саны), кеше <*> | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 0 - 200 | 25 000 | 2 000 |
| 2 | 201 - 400 | 27 000 | 3 000 |
| 3 | 401 - 700 | 31 000 | 3 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 32 000 | 4 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 35 000 | 5 000 |
| 6 | 1 801 һәм югарырак | 37 000 | 6 000 |
| <*> спорт резервын әзерләүне оештыру укчылары контингенты (спорт-җайлашу мәктәбе) 3 коэффициенты белән исәпкә алына»; | | | |

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан

Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов